**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам, 18 нче йорт.
Тел.(885552)3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬН**
**РАЙОН СОВЕТ ВЕРХНЕЯХШЕЕВСК**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево, ул. Но
дом 18. Тел.(885552) 3-44-45.
E-mail Diliya.Mirzaeva@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«18» декабрь 2024 ел** **№ 22**

Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында " 12.07.2024 ел, № 176-ФЗ Федераль законга (2024 елның 12 декабренә үзгәрешләр кертеп), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Югары Яхшый авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Югары Яхшый авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 14 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннарынан тыш, һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2_1 бүлегендә урнашкан урыннар моңа керми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Югары Яхшый авыл
җирлеге башлыгы, Совет рәисе ____________ Әхәтов И. Х.